| | |
|---|---|
| СОВЕТ КУГУШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**15 август 2023 ел** Күгеш авылы **№ 141**

Күгеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 июлендәге 45 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Күгеш авыл җирлеге Советының 2022 елның 01 сентябрендәге 87 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 № 498-ФЗ Федераль законнар, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Күгеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Күгеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Күгеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 июлендәге 45 номерлы карары (Күгеш авыл җирлеге Советының 2022 елның 01 сентябрендәге 87 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба – кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлектәге 1 нче кушымта белән тулыландырырга:

«1 нче кушымта
Күгеш авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 августындагы 141 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл

җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә

**Исемлек**
**Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗасыз кайтару тыела торган урыннар"**

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарына якын территорияләр.

6. Зират.».

2. Хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле затларның түбәндәге исемлеген билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге башлыгы;

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлегенең Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а йорт (администрация бинасы) адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендында урнаштырырга.

Күгеш авыл җирлеге башлыгы А. А. Гатауллин